## IV чирек нәтиҗәләре

*/Рәсми хәбәрләр/*

2021/2022 нче уку елының II яртыеллыгын һәм IV чиреген 50 укучы тәмамлады. Шуларның 44 нә чирек билгеләре чыгарылганнан соң белем сыйфаты 44% тәшкил итте. 4 укучы – IV сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, V сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**, X сыйныфтан **Туктамышева Әминә**, XI сыйныфтан **Насыйрова Сара** гел "5"ле билгеләренә тәмамладылар.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

*/Безнең сәяхәтләр/*

## Без инде зур үстек, 5 нчегә дә күчтек



Мәктәбебезнең IV сыйныф укучылары бер баскыч югарыга менде. Башлангыч сыйныфны уңышлы тәмамлап чыккан балаларыбызны V сыйныфка озаттык. Балачак мизгелләре тагын да күңелле булып истә калсын өчен, без, әти-әниләр, сыйныф җитәкчесе белән берлектә, балаларны төбәгебездәге иң истәлекле урын булган Хуҗалар тавына алып бардык**.**

Хуҗалар тавы безне саф урман һавасы белән каршы алды. Иң элек балаларны самоварлы табында сыйладык. Аннан соң музейга кердек. Рафик абый музейның барлык истәлекләренә игътибарыбызны юнәлтеп, кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, биредәге күргәзмәләр белән таныштырды. Борынгы башкалабыз Биләр шәһәренең нинди зур һәм бөек булганлыгына таң калдык. Музейдагы тарихи истәлекләр белән танышып, борынгы бабаларыбызның көнкүрешен, кәсепләрен белеп, истә калырлык мәгълүматлы булдык.

Музейдан чыккач балалар мәйданчыгында уйнадык. Аннан соң баскычны санап биек тау түбәсенә мендек. Табигатьнең тынлыгына, сихри матурлыгына сокланып, истәлекле фотоларга төштек**.** Балаларыбызга киләсе уку елларында бердәм һәм дус булып, башлангычта алган белем нигезләрен онытмыйча, яңа үрләр яуларга насыйп булсын иде.

***Әти-әниләр исеменнән Гөлшат Закирова***

*/Безнең спорт/*

## Май ае көрәшләре



7 майда Чистай шәһәрендә **Җиңүнең 77 еллыгына** багышланган ачык турнирда безнең көрәшче егетләрдән 25 кг авырлыкта III сыйныф укучысы **Җамалет-динов Зөлфәт I урынга**, **55 кг авырлыкта** VIII сыйныфтан **Галимов Рияз II урынга**, һәм 95 кг авырлыктагы көндәш белән көрәштә X сыйныфтан **Камалов Илдус** (60 кг) **I урынга** лаек булдылар.

22 нче май көнне район үзәге Аксубайда **Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына** багышланган милли көрәш буенча зона беренчелеге булып узды. Бәйгенең спонсорлары буларак Аксубай районы администрациясе һәм мөхтәсибәте белән берлектә безнең **Түбән Майна авылы мәчете** дә катнашты. Көраш нәтиҗәләре буенча безнең мәктәп укучыларыннан X сыйныфтан **Камалов Илдус I урынны,** III сыйныфтан **Хәбибрахманов Абдулла II урынны** алуга ирештеләр. Шулай ук, былтыр мәктәпне тәмамлап киткән укучыларыбыздан **Хәбибрахманов Ильяс – I, Гогиев Аслан – III урыннарга** ия булдылар. Бу спорт чарасын уздыруга зур өлеш керткән **авылыбыз мәчете әһелләренә** һәм көрәшче егетләрнең остазы **Илһам Камаловка** зур рәхмәтебезне белдерәбез.

## Шахмат китергән уңыш

26-29 май көннәрендә V сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** чираттагы шахмат турнирында катнашты. Турнир "Кама аръягы гран при уеннарының 3 этабы" буларак Татарстанның көчле шахматчыларын Бөгелмә шәһәрендә җыйды. Кызу уен нәтиҗәләре буенча Фаил **III урынга** лаек булып, грамота, медаль, акчалата приз белән бүләкләнде.


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе

Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина

Редколлегия әгъзалары:

Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова, Виктория Нукина, Рузилә Мөхәммәтова, Зөлфирә Сафиуллина


# Мәктәп хәбәрчесе


**№5** (№36) май 2022 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газете



Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


## 24 нче май – Соңгы кыңгырау...




Бу бәйрәм җитәсе вакытлар кайсы әти-әнинең, кайсы укытучының күңеленә тыныч урнашсын икән. Ел саен укучылар озаткан вакыт – моңсу, аерылу вакыты ул. Йөрәкләрдә укучыңа карата ихлас теләкләр, бөтен булган көчеңне аларга бирәсе килүләр... Бердәм Дәүләт Имтиханнары өчен бергә борчылулар... Тик вакыт җитә- без аларны озатабыз. Аларга алмашка яңалары килә тора. Киткән укучылар укытучы йөрәгендә барыбер саклана. Алар шатлыгы – безнең шатлык, уңышлары да безнеке, абынсалар да (Аллаһ сакласын!) безнең йөрәк сыкрап куяр.

Быел мәктәбебез тагын 11 нче сыйныфтан 4 укучысын озата. Алар һәр яктан үрнәк, тәртипле, тыңлаучан балалар булып истә калырлар. Район, республика күләмендә олимпиада, конкурс җиңүчеләре булганга гына түгел, мондый балалар мәктәпнең йөзек кашы булып торалар. Аларга ышаныч көчле, беркайчан да йөзебезгә кызыллык китермәсләр. Сара сабый чагында дәфтәр читенә карандаш белән сызып, киләчәгенә юл ярды. Ак күлмәкле, нык фикерле Халит математиканы үз итте. Сабырлыгы, тыйнаклыгы белән якын булган Фазыл һәр фәнгә тигез карады. Гадилеге, эчкерсезлеге белән яраттырган Рузилә ярдәмчеллеге белән аерылып торды. Һәр укучым үзенчәлекле булса да, уңыш һәрберсенә тигез килсен иде. Киләчәкләрендә бар да хәерлегә барсын иде дим чын йөрәктән.

IX сыйныфны 7 укучы тәмамлады. Алда әле сынаулар күп. Аларга да киләчәкләре уңыш китерсен иде. Сайлыйсы һөнәрләре, барасы урыннары җайлы, уңышлы булсын. Тормыш юлы тигез түгел, һәр адымны үлчәп атлагыз. Максатларыгызга ирешегез!



Бәйрәм тамашасы, гадәттәгечә, чыгарылыш укучыларының чыгышлары, директор, район җирлегеннән кунаклар, укытучылар, әти-әниләр котлавы белән үрелеп барды. Ветеран укытучылар, укучыларның беренче укытучылары да чыгарылышларны чын күңелдән котладылар. Бәйрәмдә катнашкан кунаклар күңелләре белән балачак илендә булганнардыр. Күзләрне дымландырган бу тантанада күңелле һәм моңсу мизгелләр күп булды. Киләсе елны I сыйныфка баручы укучылар чыгышы гына дымланган күзләрне бераз елмайтты. Күңелле тамашалары белән бәйрәм рухын күтәреп җибәрделәр.

Бәйрәмгә нокта куя торган мизгел – Чыгарылыш вальсы... Бу бию янәдән барыбызның да күңелләрне нечкәртте. Бию кое кебек тигез булса иде юлыгыз. Хәерле юл, кадерле укучыларым!

***XI сыйныф җитәкчесе Фәнүзә Гафиятуллина***

*/Мөгаллим минбәре/*

## Рус теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ белемлелеген үстерү алымнары

Бүгенге көндә гомуми белем алган укучылар аралашу һәм социаль мөнәсәбәтләрнең киң диапазонын хәл итү өчен кирәкле белем күнекмәләренә ия булырга тиеш. Бу максатка ирешүдә балаларда функциональ грамоталылык формалаштыру иң үтемле чараларның берсе булып тора.

Һәр чорда да укытучылар алдында укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү бурычы торды. Икенче буын ФДБС буенча да укучыларны төрле эшкә җәлеп итү аша, аларның фикерләвен, сөйләмен, рухи үсешен тәэмин итү бурычы билгеләнде. Без укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптырту алымнарын күздә тотып эшләргә, алган белемнәрен тормышта куллана ***(Башы, ахыры 2 нче биттә)***




*(Дәвамы, башы 1 нче биттә)*

белергә өйрәтергә тиеш. Шул очракта гына безнең укучылар яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхесләр булып үсәчәкләр.

Яңача укыту технологиясенең нигезендә укучы һәм укытучы арасында яңача мөнәсәбәт тора. Беркемгә дә сер түгел, бүгенге көн укучысы үзе теләгән әйберне генә эшли, үзенә кызык тоелган әсәрләрне генә укый. Шуның өчен безнең максат: укучыларда аңлап укуга кызыксыну уяту. Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә, аннан бала ниндидер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Ә иң мөһиме – укучылар дәреснең һәр этабында логик яки иҗади фикер йөртсен өчен шартлар тудырырга кирәк. Бу бурычларны рус теле һәм әдәбияты укытучысы нинди юллар белән тормышка ашыра ала соң? Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын куллану эшләү, укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү.

Тел укытучысы буларак, мине һәрвакыт бер сорау борчыды: "Ничек итеп укучыларда әдәби әсәрне аңлап укырга өйрәтеп була?" Укучы текстны аңлап укыган очракта гына, көтелгән нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Эзләнү нәтиҗәсендә мин **нәтиҗәле (продуктив) уку технологиясе** белән таныштым. Бу технология нигезендә текст белән эшләүне 3 этапта оештырып була:

**1. Укучыларны әсәрне кабул итәргә әзерләү, укучыларда теләк, мотивация булдыру.** Әсәрне укыр алдыннан иң элек укучыларның игътибарын әсәрнең исеменә, язылган елына, автор яшәгән чорга юнәлтәбез, яисә укылачак әсәр сюжетына туры килә торган картина тәкъдим итәбез һәм шулар буенча әңгәмә оештырабыз. Шулай ук, укылачак әсәрнең эчтәлегеннән җыелган сүзтезмәләр биреп, шулардан телдән хикәя төзетәбез. Һәрбер төркем үз хикәясен укый, авторныкына кайсы якынрак булуы әсәрне укыганнан соң чагыштырыла. Яисә, гади генә менә шундый ысулны да кулланырга мөмкин. Укучыларга тема буенча төрле картиналар тәкъдим итеп, шундый сорау куям: "Әлеге рәсемнәрне нәрсә берләштерә?" Укучылар бу шигырьләрнең авторын әйтергә, шигырьләренең исемнәрен атарга, рәсем буенча фикер алышырга тиешләр.

**2. Укучыларны текстны аңлап укуларына ирешүне тәэмин итү.** Әсәрне уку вакытында автор белән, андагы геройлар белән бәхәскә, диалогка керергә мөмкин, сүзлек эше алып барырга яисә алда нәрсә көтеләчәген укучыларның үзләреннән сорарга, фаразлатырга мөмкин. Аңлашылмаган сүзләргә, фразеологик әйтелмәләргә аңлатма бирә барырга. Төрле таблицаларны тутып барырга да мөмкин.

**3. Текстны укып чыкканнан соң, укучыларның белемнәрен, әсәрне ничек итеп аңлауларын тикшерү.** Әлбәттә,тикшерүнең дә бик күп юллары бар. Мәсәлән, тест уздыру, бер – береңә сорау бирү һ.б. Минем яратып куллана торган ысулым "Кая логика?" диеп атала. Укучыларга әсәр эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр тәкъдим итәм. Алар әсәр эчтәлегенә бәйле рәвештә бирелгән рәсемнәр буенча вакыйгаларны әйтә белергә тиешләр.

Кайвакыт укучылар укыган **әсәрнең идеясен** билгеләүдә авырсыналар. Әсәрдә үзара конфликтка кергән геройларны табып, аларга хас булган сыйфатларны билгелибез һәм чагыштырабыз. Чагыштырудан килеп чыккан аерма әсәр тукымасына салынган фикерне тәшкил итә.

Укучыларның сүз байлыгын, фикерләү сәләтен үстерү, әсәрне аңлап укуын тикшерү максатыннан **"Уйлап тап!"** уены бик үзенчәлекле. Иң элек тактага бирелгән хәрефләр җыелмасы языла. Мәсәлән: **Ура** (ул дәрестә узылачак тема белән дә бәйле була ала). Укучыларга сораулар тәкъдим ителә, алар шул сораулар аша тиешле сүзне уйлап табарга тиешләр. Сүзнең теләсә кайсы урынында шул хәрефләр булырга тиеш.

Бөек педагог В.А.Сухомлинский "Йөрәгемне балаларга бирәм" китабында болай дип яза: ***"Илһам биреп торучы уңышлары булса гына, балада белем алуга кызыксыну уяна."*** Креатив фикер йөртергә, уйларга өйрәнгән бала күбрәк иҗатка тартыла, андый баланың башына күбрәк матур фикер килә башлый. Әгәр балага бер генә китапның яки әсәрнең матурлыгын, фикер тирәнлеген күрсәтә алсаң, аны мәңгегә китап укуны яратырлык итеп тәрбияләргә мөмкин. Китап укыган баланың язу һәм сөйләм теле дә камил, эзлекле, тирән була.

***"Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, ireккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк",*** - дип язган моннан күп еллар элек Л.Н.Толстой. Бүгенгесе көндә дә бу фикерләр белән килешми мөмкин түгел. Асылда без, укытучылар, барыбыз да иҗат итәбез. Баланың ак кәгазьдәй саф күңеленә ак нур белән эзләр салабыз. Шул эзләрнең якты, мәгънәле булуы өчен гомеребез буена тырышырга, эзләнергә тиешбез.

***Раушания Нәҗметдинова, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

***/Безнең бәйрәмнәр/***

## *2 нче май – Ураза гаете*



Безнең авылда ел саен Гает бәйрәмнәре зурлап билгеләп үтелә. Укучыларга дини тәрбияне дөньяви белемнәр белән бергә бирү, әхлакый сыйфатларны ныгыту өчен төрле чаралар уздырыла. Мәктәптә соңгы елларда ураза тотучы укучылар саны да артуы шатландыра. Ураза тоту ихтыяр көче белән бергә, дини белемнәрне арттыру мөмкинлеген дә бирә.

Быел Ураза гаете 2 нче майга туры килде. Бу көнне мәктәп укучылары, укытучылары, авыл халкы, кайткан кунаклар мәчеткә җыелды. Иң элек гает бәйрәмен ачу өчен Рафик абый чыгыш ясады. Ул быелгы бәйрәмнең Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланганлыгы турында сөйләде. Шуннан соң сүз балаларга бирелде. Бакчада тәрбияләнүчеләр чыгышлырын азан яңгыратып башлап җибәрделәр. Чиратлашып Коръән сүрәләре укыдылар, төрле шигырьләр сөйләделәр. 5 нче сыйныф егетләре болгар бабайларның Ислам динен кабул ителү тантанасын сәхнәләштерделәр. Ахырдан без – өлкән сыйныф кызлары, болгар чоры шагыйре Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәрен мөнәҗәт итеп башкардык. Рафик абый бәйрәм тамашасыннан соң һәр балага гает бүләкләре – тәм-том тутырылган пакетлар өләште. Ә мәчеткә тәрәвих намазына бер калдырмый йөргәннәрне аерым билгеләп, зуррак бүләкләр тапшырды.

Гает бәйрәме коймаксыз узмый, әлбәттә, Мәктәптә эшләүче апалар, сыйдан сыгылып торган өстәл әзерләгән иделәр. Бәйрәмгә килгән һәркем бу чарада сыйланып, гает хөрмәтенә әзерләнгән тәм-томнардан авыз итте. Мондый җылы очрашулы, авыл халкын берләштергән, динебезгә якынайткан бәйрәмнәр бик күңелле үтә. Киләчәктә дә шундый очрашулар, олы бәйрәмнәр уздырылып торсын, укучыларыбыз алган дини гыйлемнәренә таянып яшәсеннәр иде.

***Зөлфирә Сафиуллина, Х сыйныф укучысы.***

## *Җиңү бәйрәме*




Һәр елның 9 нчы май иртәсендә авылыбыз үзәгендәге һәйкәл янына авылдашларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыкларын, тылдагыларның фидакарь хезмәтен искә алырга җыелышабыз. Быел дәһшәтле сугыш тәгәлләнгәнгә 77 ел тулды. Шуңа күрә сугыш елларындагы сабый балалар да хәзер инде яшьләре 80 нән узып киткән әби-бабайлар.

Быелгы Җиңү бәйрәме дә, башка еллардагы кебек үк, тантаналы шартлар-да узды. Мәктәптәге һәр укучы үз авылларындагы бәйрәм чараларында катнаштылар. Һәр авылда да бәйрәм чаралары өлкәннәрнең чыгышы белән башланды. Күп авырлыкларны җилкәләрендә күтәргән әби-бабайлар безгә тормышның, тынычлыкның кадерен белергә чакырдылар. Алар үзләре аша үткәргән кыенлыкларның башка кабатланмавын теләделәр.

Килгән авылдашларга, кайткан кунакларга балалар бакчасы һәм башлангыч сыйныф укучылары үз чыгышларын күрсәттеләр. Ахырдан "Үлемсез полк" чыгарылды. Сугыш кырларында илебез тынычлыгы, безнең имин киләчәгебез өчен башын салган авылдашларыбызны искә алдык. Никадәр яшь гомернең тыныч тормыш хакына корбан булганлыгын күрү безнең бик бәхетле икәнебезне яңадан төшендерә. Киләчәгебез имин, тыныч тормышта үзсын. Безгә тынычлык бүләк иткән ветераннарга олы рәхмәтләребез дога булып ирешсен.

***Виктория Нукина, Х сыйныф укучысы.***

***/Котлыйбыз!/***



Ямьле май аенда дөньяга килгән дуслардан V сыйныфтан **Вәлиева Мәрьямне**, VI сыйныфтан **Шичкин Алины**, IX сыйныфтан **Шичкина Каринаны**, X сыйныф укучысы **Туктамышева Әминәне** туган көннәре белән котлыйбыз. Дусларыбызга саулык, тырышлык, укуларында уңышлар теләп калабыз.

Яраткан укытучыбыз **Хәйруллина Рузилә апа** белән балалар бакчасы кече тәрбиячесе **Фәйзуллина Рушания апаны** да гомер бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Аларга исәнлек-саулык, тормыш матурлыгы, гаилә бәхете теләп калабыз!